КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1027

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия турында» 2016 ел, 17 август, 569 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 25 гыйнвар, 37 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 841 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1192 нче; 2023 ел, 26 июнь, 755 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «дәүләт программасы» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә, «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында югары белемнең белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары өчен С.З.Япеев исемендәге еллык стипендия комиссиясе составында:

Комиссия составыннан Л.Ю.Осиповарны, Н.Д.Пивоварованы, А.В.Хохоринны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Сатретдинов Дамир Рөстәм улын | Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрын, комиссия рәисен (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гуревич Альбина Эдуардовнаны | «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча республика яшьләр формированиеләре үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручыны, комиссиянең җаваплы секретарен |
| Вахитова Резеда Нәкыйп кызын | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Идарә башлыгы урынбасары – участок вәкаләтле полициясе һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру бүлеге башлыгын (килешү буенча); |

Тимур Ренат улы Камалетдиновның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча)»;

Раушан Булат улы Зариповның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин